РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.03.2026 № 325-п

2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре балаларына һәм укучыларына һөнәри юнәлеш бирү буенча «saba Balahoner «һөнәрләр шәһәре»муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында.

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 19 февралендәге 140-п номерлы «2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре балаларына һәм укучыларына һөнәри юнәлеш бирү буенча «Saba Balahoner» һөнәр шәһәре» муниципаль программасын раслау турында карары белән расланган 2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре балаларына һәм укучыларына һөнәри юнәлеш бирү буенча «Saba Balahoner» һөнәрләр шәһәре» муниципаль программасына (алга таба – программа), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспорты таблицасында «Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре | 2024-2026 елларга Программаны финанслау күләме Саба муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән 1 967,000 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча:<br>2024 ел - 720,000 мең сум;<br>2025 ел - 747,000 мең сум;<br>2026 ел - 500,000 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Саба муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш. |

»;

1.2. Программаның IV бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итү**

2024-2026 елларга Программаны финанслау күләме Саба муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән 1 967,000 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча:

2024 ел - 720,000 мең сум;

2025 ел - 747,000 мең сум;

2026 ел - 500,000 мең сум.

Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Саба муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.

2. Программаның 1 нче кушымтасын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитет
Җитәкчесе М.Р. Ишниязов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитетының №_______ карарына

1 нче кушымта
2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы
гомуми белем бирү учреждениеләре
балаларына һәм укучыларына
һөнәри юнәлеш бирү буенча
«Saba Balahoner»"
«һөнәрләр шәһәре» муниципаль программасы "

Программаны гамәлгә ашыру чаралары

| № т/б | Атамасы | Башкару вакыты проведения | Башкару өчен җаваплы затлар | Финанслау чыганагы | Финанслау күләме еллар буенча, мең сум. | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2024 | 2025 | 2026 |
| 1. Норматив-хокукый нигезне булдыру | | | | | | | |
| 1.1 | Программаны эшләү һәм раслау, Программа паспорты ясау | | Мәгариф идарәсе | Җирле бюджет | 0,000 | 47,000 | 0,000 |
| 1.2. | Һөнәри юнәлеш бирү эшчәнлеген регламентлаштыручы локаль актлар эшләү | | | | | | |
| 1.3. | Программаны гамәлгә ашыру буенча юл картасын (чаралар планын) раслау | | | | | | |
| 1.4 | Программада катнашучылар өчен паспортлар сатып алу һәм бирү | | | | | | |
| 2. Оештыру-методик ярдәм күрсәтү | | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.1. | Программада катнашучыларны транспорт белән тәэмин итү | График буенча | Мәгариф идарәсе | Җирле бюджет | 520,000 | 599,000 | 500,000 |
| 2.2. | Күчмә дәресләр үткәрү өчен предприятиеләр белән килешүләр төзү | Февраль | «Мәгариф идарәсе» МКУ, предприятие җитәкчеләре | | | | |
| 2.3. | Программага юл картасы булдыру | Февраль | «Мәгариф идарәсе» МКУ тарафыннан | | | | |
| 2.4. | Һөнәри юнәлеш бирү эше буенча айлык үткәрү | Ел саен, март аенда | Мәгариф учреждениеләре | | | | |
| 2.5. | Укучыларга һөнәри юнәлеш бирү мәсьәләләре буенча консультация бирү | Ел дәвамында | «Саба районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ, Мәгариф учреждениеләре | | | | |
| 2.6. | WorldSkills һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатында укучыларның мастер-классларында катнашуы | Август | "Балалар иҗат үзәге" Муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе<br><br>«Саба районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ, Мәгариф учреждениеләре | | | | |
| 2.7 | "Әти-әнинең эш урынында бер көн" проекты | Ел саен, каникуллар вакыты | «Мәгариф идарәсе» МКУ тарафыннан | | | | |
| 2.8 | Белем бирү учреждениеләрендә һөнәри юнәлеш бирүче стендлар, сайтлар, кабинетлар бәйгесе. | Ел дәвамында | Мәгариф идарәсе, Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. Мәгариф учреждениеләре укучылары һәм мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр белән эшләү | | | | | | |
| 3.1 | Мәгариф учреждениеләрендә фотокүргәзмәләр:<br>«Минем әти-әнием һөнәре»<br>«Минем авылның һөнәрләре»<br>«Һөнәр - кешеләргә шатлык бүләк итү»;<br>Балалар бакчасында фотокүргәзмәләр:<br>«Минем хыялым»<br>«Безнең әниләрнең һөнәрләре»<br>«Һөнәрләр төрлелеге» | Ел саен | Гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре | | | |
| 3.2. | Һөнәри юнәлеш бирүче иҗади проектлар, коллектив-иҗади эшләр бәйгесе | Ел саен | «Мәгариф идарәсе» МКУ, ОУ | | | |
| 3.3. | Рәсемнәр, иншалар бәйгесе | Ел саен | Мәктәпкәчә белем бирү, гомуми белем бирү учреждениеләре | | | |
| 3.4. | Белем бирү оешмаларының тематик чараларын үткәрү:<br>«Авылым һөнәрләре»<br>«Һөнәрләр дөньясы»<br>«Мин булырга телим...»<br>«Барлык һөнәрләр дә кирәкле, барлык һөнәрләр дә мөһим»<br>«Уңыш формуласы - сәләт буенча хезмәт» | Ел дәвамында | Мәгариф учреждениеләре | | | |
| 3.5. | Балалар бакчасында тематик чаралар үткәрү:<br>«Осталар шәһәре»<br>«Икмәк кайда туган» | Ел дәвамында | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Хезмәтнең сихере» | | | | | | |
| 4. Ата-аналар белән эшләү | | | | | | | |
| 4.1. | Һөнәри юнәлеш бирү мәсьәләләре буенча ата-аналарны консультацияләү | Ел дәвамында | «Саба районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ, Мәгариф учреждениеләре | | | | |
| 4.2. | Ата-аналар җыелышлары:<br>- «Өйдә һөнәр сайлау»<br>- «Һөнәрне сайлау нәрсә ул?»<br>- «Гаиләнең дөрес карар кабул итүдә роле» | График буенча | Мәгариф учреждениеләре | | | | |
| 4.3. | Проектлар конкурсы «Минем гаиләмнең һөнәрләр тарихы» | График буенча | "Балалар иҗат үзәге" Муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | | | | |
| 5. Район предприятиеләре һәм оешмалары белән эшләү | | | | | | | |
| 5.1. | Профориентация дәресләре - балалар белән дәресләр үткәрү | Аерым график буенча | Район предприятиеләре, районның мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү учреждениеләре | | | | |
| 5.2. | Предприятиеләргә экскурсияләр | Аерым график буенча | Мәгариф учреждениеләре | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.3. | Кызыклы һөнәр вәкилләре белән очрашулар | Ел саен | МУ, район предприятиеләре | | | | |
| 5.4. | «Мин - мастер» һөнәри осталык район конкурсын үткәрү (предприятиеләр белән берлектә)<br>. | Ел саен | "Балалар иҗат үзәге" Муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе, район предприятиеләре | | 200,000 | 101,000 | 0,000 |
| 5.5. | Җаваплы затлар, предприятиеләр остазлары өчен түгәрәк өстәлләр һәм тренинглар үткәрү. | Ел саен | «Мәгариф идарәсе» МКУ, "Балалар иҗат үзәге" Муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | | | | |
| | Барлыгы: | | | | **720,000** | **747,000** | **500,000** |

Кулланган кыскартулар:

Җирле бюджет – Саба муниципаль районы бюджеты

«Мәгариф идарәсе» МКУ – «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ

«БИҮ» ӨББ МБУ - «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Балалар иҗаты үзәге» өстәмә белем бирү МБУ

ГББУ - гомуми белем бирү учреждениеләре

МББУ – мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре